КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 сентябрь г.Казань № 727

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру турында» 2020 ел, 29 апрель, 346 нчы карары белән расланган Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру буенча ведомствоара комиссия составына үзгәрешләрне кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2020 ел, 29 апрель, 346 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 декабрь, 1157 нче; 2021 ел, 1 сентябрь, 801 нче; 2021 ел, 1 сентябрь, 801 нче; 2022 ел, 5 май, 417 нче; 2022 ел, 16 май, 446 нчы; 2022 ел, 7 июль, 651 нче; 2023 ел, 19 май, 609 нчы; 2023 ел, 6 октябрь, 1254 нче; 2024 ел, 15 март, 148 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча ведомствоара комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Ведомствоара комиссия составыннан А.Л.Анфимованы, И.Ф.Бадриевны чыгарырга;

Ведомствоара комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улын | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын, оештыру комитеты рәисе урынбасарын |
| Герасимова Гела Юрьевнаны | Татарстан Республикасы финанс министры урынбасарын |

| | |
|---|---|
| Сабурская Алина Викторовнаны | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгын |
| Сәлахиев Марат Фидаил улын | «Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе башлыгы урынбасарын (килешү буенча); |

Мищихин Александр Васильевич вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин